**Карар № 114**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы**

**“26“ май 2025 ел** **Олы Әтнә авылы**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 101 номерлы карары белән расланган Олы Әтнә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының 12.12.2024 ел, №89-ТРЗ «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы кодексының 42 маддәсенә үзгәреш кертү турында»гы, № 92-ТРЗ «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы законнарына, Әтнә районы прокуратурасының 28.04.2025 ел, №02-08-02-2025/Прдп217-25 протестына нигезләнеп, Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 101 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә"гә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1. 3 бүлекнең 3.9 пунктында** «2025 елның 1 гыйнварына» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварына» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2. 16 нчы бүлекнең 16.10 нчы пунктындагы 3 нче пунктчасын** үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваппчылыгымда калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Р.Р. Маликова